Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иске Чекалда авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иске Чекалда торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**11 ноябрь 2022 ел** **№ 1**

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 11 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта булган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән түбәндәге сорау нигезендә гражданнар җыены беркетмәсе төзелде, «Иске Чекалда авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иске Чекалда торак пункты террито-риясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакы-тлы хезмәткә чакырылган затлардан, ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыены кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы":

1. Иске Чекалда авылында күмү урыннарын карап тоту буенча чаралар:

- зиратны кыймалау өчен, контейнер мәйданчыгы өчен, зират территориясендә гомуми файдалану урынын төзекләндерү өчен материал сатып алу һәм хезмәт килешүе буенча эшләр өчен түләү;

2. Иске Чекалда авылын төзекләндерү чаралары:

- урам утлары өчен лампалар, фонарьлар һәм чыгым материаллары сатып алу, агымдагы ремонт ясау, хезмәт килешүе буенча эшләр өчен түләү;

3. Иске Чекалда авылында юл эшчәнлеге чаралары:

- грейдлау, урамнарны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу һәм килешү буенча эш өчен түләү.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 179 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 93 кеше, бу – 52% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 93 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен тавыш бирүчеләр юк.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иске Чекалда авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иске Чекалда торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. 2023 елда Әгерҗе муниципаль районының «Иске Чекалда авыл җирлеге» Иске Чекалда торак пункты территориясендә, I төркем инвалидларыннан, ялгыз картлардан (80 яшькә җиткәннәр), көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган затлардан һәм шәхесләрдән тыш иректән мәхрүм итү урыннарында булганнардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә.

3. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1. Иске Чекалда авылында күмү урыннарын карап тоту буенча чаралар:

- зиратны кыймалау өчен, контейнер мәйданчыгы өчен, зират территориясендә гомуми файдалану урынын төзекләндерү өчен материал сатып алу һәм хезмәт килешүе буенча эшләр өчен түләү;

2. Иске Чекалда авылын төзекләндерү чаралары:

- урам утлары өчен лампалар, фонарьлар һәм чыгым материаллары сатып алу, агымдагы ремонт ясау, хезмәт килешүе буенча эшләр өчен түләү;

3. Иске Чекалда авылында юл эшчәнлеге чаралары:

- грейдлау, урамнарны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу һәм килешү буенча эш өчен түләү.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Чекалда авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Авыл җирлеге башлыгы П.М.КОРОЛЕВ